Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең
Наратлы авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

21ноябрь 2025 ел №5

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль Законның 45,69 статьялары нигезендә,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2025 елның 21 ноябрендә18 сәгать 00 минутта булган гражданнарның җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең Наратлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сумкүләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Коралды Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәтне узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаиләәгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә җибәрү белән килешәсезме:
торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлын норматив хәлгә китерү)?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 63 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 34 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 29«РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 5«КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Наратлыавыл җирлегенең Иске Михайловка авылы гражданнар җыенын узган дип таныырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.«Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең Наратлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Коралды Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәтне узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә җибәрү белән килешәсезме:торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлын норматив хәлгә китерү)?»турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип таныырга.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Иске Михайловка авылы, Школьнаяурамы, 43 йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йортытерриториясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул

ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Зарубин